КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 15 сентябрь г.Казань № 1129

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 май, 349 нчы; 2015 ел, 30 март, 198 нче; 2016 ел, 24 март, 165 нче; 2017 ел, 22 апрель, 238 нче; 2018 ел, 9 апрель, 224 нче; 2018 ел, 10 сентябрь, 766 нчы; 2019 ел, 22 март, 214 нче; 2019 ел, 29 май, 455 нче; 2020 ел, 13 февраль, 106 нчы; 2020 ел, 12 июнь, 484 нче; 2021 ел, 23 март, 154 нче; 2021 ел, 3 август, 677 нче; 2022 ел, 28 февраль, 176 нчы; 2022 ел, 7 июнь, 529 нчы; 2023 ел, 11 март, 233 нче; 2023 ел, 21 июль, 878 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгын дәүләт программасының җаваплы башкаручы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта:

«чираттагы финанс елына» сүзләреннән соң «һәм план чорына» сүзләрен өстәргә;

«Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2025 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарга теркәлгән исемлек буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин